БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» 12 2022 ел № 343

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәтләр күрсәтү бәясен һәм исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 һәм 22 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәтләр күрсәтү бәясен һәм исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «03» 12
343 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе һәм исемлеге

| т/б № | Хезмәтнең атамасы | III - V категориядәге юл |
|---|---|---|
| | | Бәясе, сум |
| 1. | Җәмәгать тукλануы пунктын (кафе, ресторан һ.б.), кибетне кушу | 35 803,68 |
| 2. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен (шиномонтаж) кушу | 30 921,36 |
| 3. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен (ремонт, юу урыны) кушу | 39 058,56 |
| 4. | Базар (оешкан сәүдә нокталары) кушу | 39 058,56 |
| 5. | Транспорт чараларын куеп тору урыннарын һәм туктап тору урыннарын (юл сервисы объектларында) кушу | 26 039,04 |
| 6. | Автомобильгә ягулык салу станциясен кушу | 47 195,76 |
| 7. | Юл сервисы комплексын кушу | 47 195,76 |
| 8. | Автомобильгә ягулык салу станциясе белән юл сервисы комплексын кушу | 56 960,4 |
| 9. | Сәүдә комплексын кушу | 47 195,76 |
| 10. | Йөк автотранспортына хезмәт күрсәтүче биналарны һәм корылмаларны (йөк автомобильләре станцияләре, терминаллар, түләүле автомобиль туктау урыннары һ.б.) кушу | 52 078,08 |